**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп туры биремнәре**
**2020/2021 уку елы,11 нче сыйныф**

**Олимпиадные задания школьного тура по татарскому языку для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке**
**(для изучающих татарский язык)**
**2020/2021 учебный год, 11 класс**

*Максимальный балл – 131 б.*

*Время выполнения – 120 минут*

**I. Устная часть.**

**Назовите и составьте рассказ по картине (10– 12 предл., по 3 б.=36 б.+2 б=38 б.).**



**II. Письменная часть.**

**1.Прочитайте текст и выполните задания.**

1) ***Озаглавьте текст (3 б.).***

***2) Запишите пропущенные послелоги ( по 2 б. = 12 б.).***

***3) Запишите синонимы выделенных слов (по 3 б. = 18 б)***

Әтиле-уллы поездга утыралар. **Улы** тәрәзә янындагы урынны сайлый. Поезд кузгалып киткәч, 25 яшьләрдәге бу егет сокланып һәм бик кызыксынып агачларны, өйләрне, кырларны күзәтә башлый.

- Әти, кара әле, агачлар әйтерсең безнең арттан чаба! Ә җир әйләнә ... , Бигрәк кызык, әйеме! -ди.

Әтисе сүзсез генә елмая. Ә янәшәдә утыручы ир ... хатын бер-берсенә карашып ала. Буй җиткән егетнең үзен 4-5 яшьлек бала ... тотуына **аптырый** алар. Егет тагын да гаҗәпләнгән тавыш ... :

- Әти, суга кара әле, суда кошлар йөзеп йөри,- ди, үрдәк бәбкәләренә күрсәтеп.

Бераздан тагын гаҗәпләнүен яшерә алмыйча:

- Болытлар бигрәк матур, әйеме, әти. Әйтерсең, алар поезд артыннан калмыйк дип **чабалар**, - ди.

**Беркадәр вакыттан** ... җил көчәя, яңгыр сибәли башлый. Егет ачык тәрәзәдән кулын суза, ә инде учына яңгыр тамчылары төшүен күреп исе китә һәм, бу юлы да хисләрен яшерә алмыйча, атасына эндәшә:

- Әти, кара әле, кулыма яңгыр тама, яңгыр, –ди.
- Ә әтисе гел сүзсез генә елмаеп улын күзәтүен дәвам итә, Бу хәлгә исләре китеп утырган ир ... хатын түзмиләр, ата кешегә:
- Ни өчен улыгызны психологка күрсәтеп карамыйсыз, бәлки берәр дәвасы табылыр иде, - диләр.

Әти кеше тыныч кына:

- Дәваланып кына чыктык әле. **Хастаханәдән** өйгә кайтып барышыбыз. Сукыр иде ул. Әле менә яңа күрә башлады.

Без кешеләр, күп вакытта **хаталанабыз** шул: төп сәбәпне белмичә, нәтиҗә ясап куярга ашыгабыз.

***4) Напишите ответы на вопросы*** *(по 3 б.=9 б.)*.

- Бу вакыйга кайда һәм кайчан була?
- Хикәядә нинди контраст күренеш чагылдырыла?
- Хикәянең геройлары ни өчен телсез калган кебек булалар?

***5) Напишите небольшой рассказ, основываясь на последнее предложение текста (3-5 предложений, по 3 б. =15 б.)***

**2. Напишите подходящие реплики на татарском языке (по 2 б = 8 б.).**

1) Спросите у учителя о том, когда состоится родительское собрание.

2) Сообщите другу (подруге), если в выходные погода будет хорошая, то вы всей семьей пойдете на каток.

3) Сообщите маме о том, что вы с классом на каникулах поедете в поход.

4) Предложите сестре сходить вместе на премьеру нового фильма.

**3. Прочитайте, отгадайте загадки и запишите ответы (по 3 б. = 6 б.)**

1) Берсе яшел keләм тукый,

Берсе сарыга мана.

Берсе ак мамыгын түши,

Ә берсе җыеп ала.

2) Ике аяк та түгәрәк,

Куышалар тәгәрәп;

Үзем утырам, үзем чабам

Теләсәм кая табан.

**4. Запишите подходящие прилагательные-антонимы (по 2 б. = 10 б.)**

**1.** ___________________ кырмыска - ______________________ фил.

2. ______________________ дару - _________________________ чәй.

3. _____________________ таш - _______________________ шар.

4. ____________________ сукмак - _________________________ юл.

**5. Запишите пропущенные слова (по 1 б. = 12 б.)**

1.Унынчы ... утыз алты укучының ... үз холкы, үз сәләте, үз теләге, үз омтылышы бар иде. 2. ... үзләренең ... һөнәрләрен ышаныч белән сайлаганнар, ... әле ныклы бер ... юк. 3. Бик ... укучылар, Петр Ильичның ... буенча, педагогия институтын ... . 4. Ул укучыларының инициативасын ... , кулыннан килгән кадәр ... сайларга ... иде.

*Сүзләр:* ***чикләмичә, бердүләр, туры юлны, һәрберсенең, сайладылар, күп, фикер, киңәше, булачак, булыша, икенчеләрендә, сыйныфтагы.***